СОВЕТ АЛБАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.28, с. Албай, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422176

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, Албай авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422176

тел.(факс): (85563) 3-05-08; e-mail: Alb.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

17.09.2018 ел. № 6-34

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Албай авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл жирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру:

- Албай торак пунктында зират ягына баручы юлны, Югары Әрнәш торак пунктында Максимов урамы ягына баручы юлны вакташ җәеп ремонтлау;
- авыл җирлегенә караучы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башлыгы И.П.Крешковка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Албай авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе Крешков И.П.